РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 07 2018 г. №455

Ютазы муниципаль районы
территориясендә киселгән
агачларның бәясен һәм компенсацион
яшелләндерүнең бәясен исәпләү
Методикасын раслау турында

2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131 Федераль законга ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1.Ютазы муниципаль районы территориясендә киселүче яшел утыртмаларның һәм компенсацион яшелләндерү уздыруның бәясен исәпләү Методикасын расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының www.http://jutaza.tatarstan.ru рәсми сайтында “Норматив документлар” бүлегендә бастырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

С.П. Самонина

2018 елның ____нән №___
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта

**Ютазы муниципаль районы территориясендә киселгән яшел утыртмаларның һәм компенсацион яшелләндерүне уздыру бәясен исәпләү Методикасы**

**1статья. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Киселүче яшел утыртмаларның һәм компенсацион яшелләндерү уздыруныц бәясен исәпләү методикасы (алга таба – текст буенча – Методика) Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федедерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 131 санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, 2002 елның 10 гыйнварыннан булган “Әйләнә-тирә мохитны саклау турында”гы №7 Федераль Законына, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июленнән булган “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45 Законына ярашлы эшләнде.

1.2. Методика Ютазы муниципаль районы территориясендәге яшел утыртмаларны компенсацион яшелләндерү өчен хаклы рәвештә юк иткәндә, шулай ук яшел агачларга хаксыз рәвештә зыян салганда яки юк иткәндә компенсацион яшелләндерү өчен муниципаль берәмлек бюджетына кертелергә тиеш булган түләүләрне исәпләү өчен билгеләнгән.

1.3. Методика түбәндәге очракларда кулланыла:

- Ютазы муниципаль районы территориясендә яшел үсентеләргә кагылган хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда килеп туарга мөмкин булган потециаль зарарны бәяләү өчен инвестицион проектларның тирә-юнь мохитка тәэсир итү һәм аларның экологик экспертизасын әзерләү процессында;
- хаклы рәвештә киселгән яшел утыртмалар өчен түләү күләмен табигать факторларын, шулай ук яшелләндерү объектларының экологик әһәмиятен исәпкә алып исәпләгәндә;
- хаксыз рәвештә зарарлау яки яшел утыртмаларны юк итү нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплаганда (агачның, үсемлекнең үсүе туктау дәрәҗәсенә кадәр түгел);
- Ютазы муниципаль районы территориясендә булган яшел үсентеләрнең бәясен билгеләү белән бәйле башка очракларда.

1.4. Әлеге Методика үзенец тәэсирен урман законычалыгын бозу нәтиҗәсендә урманнарга, шул исәптән урман утыртмаларына, яки урман утыртмалары булып тормаган агачларга, куакларга һәм лианаларга ясамый.

**2 статья. Юк ителгән (киселгән) яшел утыртмаларны классификацияләү һәм идентификацияләү һәм аларның бәясен билгеләү**

2.1. Юк ителүче (киселүче) шәһәр яшел утыртмаларының төп төрләренең бәясен исәпләү өчен функциональ билгеләнешенә, урнашкан урынына, милек формасына һәм шәһәр территорияләренең кайсы ведомствога каравына бәйләнмәгән рәвештә үсемлекләрнең түбәндәге классификациясе кулланыла:

- агачлар;
- куаклар (күпләп яки аерым утырту);
- куаклардан “тере читәннәр”;
- үлән япмасы (газоннар һәм табигый үлән);
- чәчкә түтәлләре.

2.2. Үсемлекләргә салынган зыянны билгеләгәндә, ботаник, урман төзелеше, дендрологик, геоботаник, туфрак-мелиоратив, геологик һәм башка тикшеренүләр, урман һәм үсемлек кадастрлары, үсемлекләр мониторингы, шулай ук үсемлекләр торышы турында тиешле мәгълүматы булган дәлилләр кулланыла.

Үсемлекләргә ясалган зарарны каплау гражданнар, шәхси эшмәкәрләр, оештыру-хокукый формаларына бәйләнмәгән рәвештә оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Яшел утыртмаларны хаксыз рәвештә зарарлау яки юк итү (кисү) очрагында, өстәмә тикшеренүләр уздыру буенча чыгымнар өчен, экспертлар җәлеп иткән өчен түләү, исәп-хисап уздыру, документлар тутыру экологик хокук бозучы зат акчасы хисабына гамәлгә ашырыла.

2.3. Агач-куак, үлән төрендәге үсемлекләргә ясалган зыян күләмен билгеләгәндә, түбәндәгеләр исәпкә алына:

- агачлар һәм аерым торган куаклар өчен – данәләрдә, һәм, аерым үсемлекләр санын билгеләү шактый авыр булган очракта, куаклыклар һәм үсентеләр өчен погон метрларда;
- үлән үсемлеге биләгән мәйдан, квадрат метрларда;
- агачларның һәм куакларның төре, токымы (яфраклымы яки ылыслымы), үлән үсемлекләренең төре;
- 1,3 метр биеклектәге агач кәүсәсенең диаметры, агач биеклеген, төрен (разряд), бер берәмлек агачтан алынган үзагач (древисина), бер кубик метр агачның хакын бәяләү. Әгәр агачның берничә кәүсәсе бар һәм икенче дәрәҗәдәге кәүсәсенең диаметры 8 сантиметрга җиткән икән, һәр кәүсәсе аерым агач булып исәпләнә;
- әлеге үсемлекне утырту һәм карау буенча башкарылган эшләр бәясе;
- 1 метрга кадәр биеклектәге үсентенең сумнарда бәясе;
- үсемлекнең торышы һәм аның кыйммәте;
- үсемлекләрнең деградациясе дәрәҗәсе (яшел үсентеләрне санкцияләнмәгән зарарлау яки юкка чыгару (кисү) юлы белән бетергәндә (при уничтожении) исәпләгәндә кулланыла.

2.4. Яшел утыртмаларны юкка чыгарганда зыян (зарар) күләме түбәндәге формулалар белән исәпләнә:

| N т/б | Яшел утыртмалар | Зыян (зарар) күләмен исәпләү формуласы* | Шартлы билгеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | Агач | $Y=\left(C+Ц+C_v\right)\times q\times k_1\times k_2\times k_ц\times$<br>где $C_v=V\times C_д^3$ | Y – зарар күләме<br>C – 1 данә агачны утырту һәм үстерү буенча эшләр (таб. 1)<br>Ц – 1 үсентенең бәясе (таб. 1)<br>Cv – алынган үзагач күләме бәясе<br>V – 1данә агачтан алынган үзагач күләме бәясе<br>Сд3 - 1 куб. метр үзагачның бәясе<br>q – юкка чыгарылган агачлар саны данәсе<br>k1 – үсемлекләрнең мохитны саклау сыйфатын исәпкә алучы коэффициент (таб. 3)<br>k2 – үсемлекләрнең торышын исәпкә алучы коэффициент (таб. 4)<br>kң – үсемлекләрнең кыйммәтен исәпкә алучы коэффициент (таб. 5)<br>kд – үсемлекләрнең деградациясе коэффициенты (таб. 6) |
| 2 | Куаклыклар, лианалар | $Y=\left(C+Ц\right)\times q\times k_1\times k_2\times k_ц\times k_д$ | Y – зыян күләме<br>C – 1 данә яки 1 пог. метр куак һәм лиана утырту һәм үстерү буенча эшләр бәясе (таб. 2)<br>Ц – утырту материалының бәясе (таб. 2)<br>q – юкка чыгарылган лианалар, куаклыклар саны данәсе<br>k1 – үсемлекләрнең мохитны саклау сыйфатын исәпкә алган коэффиңиент (таб. 3)<br>k2 – үсемлекләрнең торышын исәпкә ала торган коэффициент (таб. 4)<br>kц – үсемлекнең кыйммәтен бәяләүче коэффициент (таб. 5)<br>kд – үсемлекләрнең деградациясе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | коэффициенты (таб. 6) |
| 3 | Газоннар, чәчкә түтәлләре | $Y=(C+Ц)\times S\times k_1\times k_2\times k_ц\times k_д$ | Y – зыян күләме<br>С - 1 кв. м газонга үлән чәчү, чәчкә түтәленә чәчкәләр утырту буенча хезмәтләр бәясе (таб. 2)<br>Ц – утырту (чәчү) материалының бәясе (таб. 2)<br>S – юкка чыгарылган газонның, чәчкә түтәленең коэффициенты<br>k1 – үсемлекләрнең мохитны саклау үзлекләре коэффициенты (таб. 3)<br>k2 – үсемлекләр торышын исәпкә алучы коэффициент (таб. 4)<br>kц – үсемлекләрнең кыйммәтен исәпкә алучы коэффициент (таб. 5)<br>kд – үсемлекләрнең деградациясе коэффициенты (таб. 6) |
| 4 | Табигый юл белән үскән үлән | $Y=S\times k_1\times k_2\times k_ц\times k_д$ | Y - зыян күләме<br>S – юкка чыгарылган табигый юл белән үскән үлән мәйданы<br>k1 – үсемлекләрнең мохитны саклау үзлеген исәпкә ала торган коэффициент (таб. 3)<br>k2 – үсемлекләр торышын исәпкә ала торган коэффициент (таб. 4)<br>kц - үсемлекләрнең кыйммәтен исәпкә ала торган коэффициент (таб. 5)<br>kд - үсемлекләрнең деградациясе коэффициенты (таб. 6) |

*Яшел утыртмаларны юкка чыгарганда зыян (зарар) күләме аңа кадәр булган чорда тауарларга (эшкә, хезмәтләргә) куллану бәяләре үзгәрүен исәпкә алучы коэффициент-дефляторны күздә тотып үзгәртелергә тиеш.

**Таблица 1**

**Агач төрендәге үсемлекләргә ясалган зыянны билгеләү өчен күрсәткечләр**

| Аскы яктан 1,3 м биеклектә кәүсә диаметры (d), см | Агачның биеклеге (h), м | Биеклек буенча разряд | 1 берәмлек агачка кулланылыштан алынган үзагач күләме (V), куб. м | Стоимость 1 куб. м үзагачның бәясе (Сд), сум | Утырту һәм карау буенча башкарылган эшләр бәясе НДСтан башка (С), сум | 1 метрга кадәр 1 үсентенең бәясе (Ц), сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Яфраклы агач төрләре** | | | | | | |
| **Имән** | | | | | | |
| 8 дән 10 га кадәр | 5 | III | 0,023 | 1200,0 | 2690,3 | 501,5 |
| 10нан 12гә кадәр | 7 | | 0,043 | | | |
| 12дән 14кә кадәр | 9 | | 0,072 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 11 | | 0,112 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 13 | | 0,164 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 14 | | 0,219 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 16 | | 0,29 | | | |
| 24тән 28гә кадәр | 18 | | 0,46 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 20 | | 0,68 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 21 | | 0,94 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 22 | | 1,23 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 23 | | 1,56 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 44тән 48гә кадәр | 26 | | 2,10 | | | |
| 48 дән 52гә кадәр | 27 | | 2,53 | | | |
| 52 дән 56га кадәр | 27 | | 3,00 | | | |
| 56 дан 60ка кадәр | 28 | | 3,52 | | | |
| 60тан 64кә кадәр | 28 | | 4,08 | | | |
| 64тән 68гә кадәр | 28 | | 4,65 | | | |
| 68 дән 72гә кадәр | 28 | | 5,27 | | | |
| от 72 дән 76га кадәр | 28 | | 5,92 | | | |
| 76дан 80гә кадәр | 28 | | 6,61 | | | |
| 80нән 84кә кадәр | 28 | | 7,35 | | | |
| 84тән 88гә кадәр | 28 | | 8,13 | | | |
| 88дән 92гә кадәр | 28 | | 8,92 | | | |
| 92дән 96га кадәр | 29 | | 9,81 | | | |
| 96дан 100гә кадәр | 29 | | 10,70 | | | |
| 100дән артык | 29 | | 11,63 | | | |
| **Юкә** | | | | | | |
| 8 дән 12гә кадәр | 6 | III | 0,019 | 489,6 | 2690,3 | 501,5 |
| 12 дән 16га кадәр | 9 | | 0,061 | | | |
| 16 дан 20гә кадәр | 12 | | 0,13 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 14 | | 0,23 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 24тән 28гә кадәр | 15 | | 0,35 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 17 | | 0,52 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 18 | | 0,71 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 19 | | 0,89 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 19 | | 1,16 | | | |
| 44тән 48гә кадәр | 20 | | 1,40 | | | |
| 48дән 52гә кадәр | 21 | | 1,69 | | | |
| 52дән 56га кадәр | 21 | | 2,00 | | | |
| 56дан 60ка кадәр | 21 | | 2,34 | | | |
| 60тан 64кә кадәр | 22 | | 2,68 | | | |
| 64тән 68гә кадәр | 22 | | 2,98 | | | |
| 68дән 72гә кадәр | 22 | | 3,042 | | | |
| 72дән артык | 22 | | 3,85 | | | |
| **Каен** | | | | | | |
| 10нан 12гә кадәр | 10 | II | 0,053 | 489,6 | 2690,3 | 501,5 |
| 12дән 14кә кадәр | 11 | | 0,080 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 12 | | 0,117 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 14 | | 0,164 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 15 | | 0,218 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 16 | | 0,28 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| от 24 до 28 | 18 | | 0,43 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 18 | | 0,61 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 19 | | 0,83 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 20 | | 1,09 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 21 | | 1,40 | | | |
| 44тән 48гә кадәр | 22 | | 1,76 | | | |
| 48дән 52гә кадәр | 23 | | 2,17 | | | |
| 52дән артык | 24 | | 2,64 | | | |
| **Усак, зирек, чаган, корыч-агач, карама, тирәк, тал һәм башкалар** | | | | | | |
| 10нан 12гә кадәр | 11 | Усак, зирек - II, барлык калганнары - III | 0,057 | усак - 489,6, барлык калганнары - 200,6 | 2690,3 | 501,5 |
| 12дән 14кә кадәр | 13 | | 0,093 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 14 | | 0,133 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 15 | | 0,185 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 16 | | 0,254 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 17 | | 0,33 | | | |
| 24тән 28гә кадәр | 19 | | 0,50 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 20 | | 0,71 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 22 | | 0,99 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 23 | | 1,30 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 23 | | 1,61 | | | |
| 44тән 48гә | 24 | | 2,02 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| кадәр | | | | | | |
| 48дән 52гә кадәр | 25 | | 2,50 | | | |
| 52дән артык | 25 | | 2,91 | | | |
| **Ылыслы агач төрләре** | | | | | | |
| **Нарат** | | | | | | |
| 8дән 10га кадәр | 8 | II | 0,027 | 920,4 | 2690,3 | 708,0 |
| 10нан 12гә кадәр | 10 | | 0,049 | | | |
| 12дән 14кә кадәр | 11 | | 0,076 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 14 | | 0,118 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 15 | | 0,166 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 16 | | 0,23 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 18 | | 0,30 | | | |
| 24тән 28гә кадәр | 20 | | 0,47 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 22 | | 0,67 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 23 | | 0,91 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 24 | | 1,17 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 24 | | 1,47 | | | |
| 44тән 48гә кадәр | 25 | | 1,81 | | | |
| 48дән 52гә кадәр | 25 | | 2,17 | | | |
| 52дән 56га кадәр | 25 | | 2,55 | | | |
| 56дан 60ка кадәр | 25 | | 2,97 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 60тан 64кә кадәр | 25 | II | 3,41 | 920,4 | 2690,3 | 708,0 |
| 64тән 68гә кадәр | 25 | | 3,88 | | | |
| 68дән 72гә кадәр | 26 | | 4,40 | | | |
| 72дән 76га кадәр | 26 | | 4,93 | | | |
| 76дан 80гә кадәр | 26 | | 5,48 | | | |
| 80нән артык | 26 | | 6,09 | | | |
| **Чыршы** | | | | | | |
| 8дән 10га кадәр | 5 | II | 0,027 | 920,4 | 2690,3 | 708,0 |
| 10нан 12гә кадәр | 8 | | 0,049 | | | |
| 12дән 14кә кадәр | 10 | | 0,076 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 12 | | 0,118 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 14 | | 0,166 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 15 | | 0,23 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 17 | | 0,30 | | | |
| 24тән 28гә кадәр | 19 | | 0,47 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 21 | | 0,67 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 23 | | 0,91 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 24 | | 1,17 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 25 | | 1,47 | | | |
| 44тән 48гә кадәр | 26 | | 1,81 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 48дән 52гә кадәр | 27 | | 2,17 | | | |
| 52дән 56га кадәр | 28 | | 2,55 | | | |
| 56дан 60ка кадәр | 28 | | 2,97 | | | |
| 60тан 64кә кадәр | 28 | | 3,41 | | | |
| 64тән 68гә кадәр | 29 | | 3,88 | | | |
| 68дән артык | 26 | | 4,40 | | | |
| **Ак чыршы** | | | | | | |
| 8дән 10га кадәр | 5 | II | 0,018 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |
| 10нан 12гә кадәр | 7 | | 0,036 | | | |
| 12дән 14кә кадәр | 8 | | 0,070 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 10 | | 0,102 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 12 | | 0,150 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 13 | | 0,201 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 15 | II | 0,27 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |
| 24тән 28гә кадәр | 16 | | 0,65 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 19 | | 0,91 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 21 | | 1,19 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 22 | | 1,51 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 24 | | 1,87 | | | |
| 44тән 48гә кадәр | 26 | | 2,27 | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 48дән 52гә кадәр | 27 | | 2,70 | | | |
| 52дән 56га кадәр | 27 | | 3,11 | | | |
| 56дан 60ка кадәр | 27 | | 3,75 | | | |
| 60тан артык | 27 | | 3,90 | | | |
| **Карагач (лиственница)** | | | | | | |
| 10нан 12гә кадәр | 11 | II | 0,068 | 920,4 | 2690,3 | 800,0 |
| 12дән 14кә кадәр | 13 | | 0,105 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 14 | | 0,150 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 17 | | 0,209 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 18 | | 0,276 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 19 | | 0,36 | | | |
| 24тән 28гә кадәр | 21 | | 0,55 | | | |
| 28дән 32гә кадәр | 24 | | 0,80 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 26 | | 1,08 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 27 | | 1,43 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 28 | | 1,81 | | | |
| 44тән 48гә кадәр | 29 | | 2,23 | | | |
| 48дән 52гә кадәр | 30 | | 2,68 | | | |
| 52дән артык | 30 | | 3,17 | | | |
| **Эрбет агачы (кедр)** | | | | | | |
| 10нан 12гә | 10 | II | 0,053 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| кадәр | | | | | | |
| 12дән 14кә кадәр | 11 | | 0,080 | | | |
| 14тән 16га кадәр | 12 | | 0,117 | | | |
| 16дан 18гә кадәр | 14 | | 0,164 | | | |
| 18дән 20гә кадәр | 15 | | 0,218 | | | |
| 20дән 24кә кадәр | 16 | | 0,28 | | | |
| 24тән 28гә кадәр | 18 | II | 0,43 | 920,6 | 2690,3 | 800,0 |
| 28дән 32гә кадәр | 18 | | 0,61 | | | |
| 32дән 36га кадәр | 19 | | 0,83 | | | |
| 36дан 40ка кадәр | 20 | | 1,09 | | | |
| 40тан 44кә кадәр | 21 | | 1,40 | | | |
| 44 до 48 | 22 | | 1,76 | | | |
| от 48 до 52 | 23 | | 2,17 | | | |
| более 52 | 24 | | 2,64 | | | |

**Таблица 2**

**Куаклы һәм үлән үсемлекләренә салынган зыянны билгеләү өчен күрсәткечләр**

| N т/б | Яшел утыртмалар | Үлчәү берәмлеге | НДСтан башка утырту һәм карау буенча башкарылган эшләр бәясе | Утырту материалының бәясе (Ц) |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Куаклыкларныц яфраклы төрләре** | | | | |
| 1 | “Тере читән” | 1 пог. метр өчен сум | 469,43 | 500,0 |
| 2 | Аерым куаклар | 1 данә өчен сум | 313,1 | 150,0 |
| **Куакларның ылыслы төрләре** | | | | |
| 1 | Аерым куаклар | 1 данә өчен сум | 461,6 | 600,0 |
| **Лианалар** | | | | |
| 1 | Аерым экземплярлар | 1 данә өчен сум | 313,1 | 150,0 |
| **Газоннар** | | | | |
| 1 | Болын үләннәреннән торган табигый үсемлекләр | 1 кв. метр өчен сум | | |
| 2 | Чүп үләннәреннән торган табигый үсемлекләр | 1 кв. метр өчен сум | | |
| 3 | Газоннар (газон үләннәре орлыкларын чәчеп) | 1 кв. метр өчен сум | 74,43 | 85,0 |
| 4 | Рулон газоны | 1 кв. метр өчен сум | 200,0 | 100,0 |
| **Чәчәк түтәлләре** | | | | |
| 1 | Чәчәк түтәлләре | 1 кв. метр өчен сум | 650,0 | Чәчәкле - декортив үсемлекләр нең сортларына бәйле рәвештә |

**Таблица 3**

**Үсемлекләрнең мохитны саклау үзлекләрен исәпкә алган коэффициентның әһәмияте (k1)**

| Исеме | k1 әһәмияте |
|---|---|
| Гомуми файдаланудагы утыртмалар | 2 |
| Чикләнгән файдаланудагы утыртмалар | 1,5 |
| Махсус файдаланудагы утыртмалар | 1 |

**Таблица 4**

**Үсемлекләрнең торышын исәпкә алучы коэффиңиентның әһәмияте (k2)**

| Үсемлекләрнең торышы | Үсемлекнең торышы аның яфраклары күплеге дәрәҗәсенә бәйле | k2 әһәмияте |
|---|---|---|
| Яхшы (утыртмалар сәламәт) I | 100% яфрак | 2 |
| Уртача II | 90-70% яфрак | 1,5 |
| Яфраклары нык кимегән III | 60-40% яфрак | 1 |
| Корып баручы IV | 30-20% яфрак | 0,5 |
| Корып бетеп баручы V | 20-10% яфрак | 0,1 |
| Корып беткән VI | Яфраклары юк | 0 |

**Таблица 5**

**Үсемлекнең кыйммәтен исәпкә алучы коэффициентның әһәмияте (kц)**

| Кыйммәтлелек төркеме | Агачлар һәм куаклар төрләре | Kц әһәмияте |
|---|---|---|
| 1-нче төркем (аеруча кыйммәтле) | - ылыслы, мәңге яшел агачларның барлык төрләре, шул исәптән: эрбет агачы, нарат, чыршы, ак чыршы, карагач;<br>- яфраклы агачларның кайбер төрләре, шул исәптән: имән, корыч-агач, зирек, карама, элмә агачы | 1,5 |
| 2-нче төркем (кыйммәтле) | - ылыслы куакларның барлык төрләре;<br>- яфраклы агачларның кайбер төрләре, шул исәптән: юкә, каен, чаган | 1,2 |
| 3-нче төркем (аз кыйммәтле) | - агачларның калган төрләре һәм яфраклы куаклар | 1 |

**Таблица 6**

**Үсемлекләрнең деградациясе коэффициенты әһәмияте (kд)**

| Үсемлекнең торышы | Деградация дәрәҗәсе | Kд әһәмияте |
|---|---|---|
| Корыган (тулы деградация, эштән чыккан) | 100% | 3 |
| Корып бетеп баручы (шактый зур деградация кичергән, “терелә” алмый) | 99%-90% | 2,5 |
| Бик корыган (көчле деградация) | 89%-60% | 2 |
| Нык корыган (уртача деградация) | 59%-30% | 0,9 |
| Уртача дәрәҗәдә корыган (бераз деградацияләнгән) | 29%-10% | 0,5 |

| | | |
|---|---|---|
| Сәламәт (зур булмаган деградация) | 9%-1% | 0,1 |

**3 статья. Киселгән яшел утыртмалар өчен акча кертү һәм сарыф итү тәртибе**

3.1. Киселүче яшел утыртмалар өчен акча түбәндәгеләр хисабына барлыкка килә:
-киселүче яшел утыртмалар өчен түләүләр;
-яшел утыртмаларны законсыз кискән өчен салынган зыянны каплау (компенсация);
-яшел утыртмаларга салынган зыян өчен административ хокук бозулар турында закончалыкка ярашлы салынган штрафлар;
- яшел утыртмаларны саклау һәм үстерү максатларына гражданнарның һәм юридик затларның, шул исәптән чит ил кешеләренең, ирекле кертемнәре;
- башка чыганаклардан керемнәр;
3.2. Яшел утыртмаларга законсыз рәвештә зыян салганда, зарарны каплау акчасы штрафлар, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән яки суд карары буенча, административ хокук бозулар турында беркетмәләр нигезендә кертелә. Югарыда әйтелгән түләүләр күләме, Методикага ярашлы рәвештә, юк ителгән үсемлек бәясенең биш тапкыр арттырылган күләмендә һәм һәр зарар салынган үсемлек өчен ½ тапкыр арттырылган күләмдә түләттерелә.
3.3. Юк ителгән яшел утыртмалар өчен кергән акча бетерелгән яки зарарланганнарына алмашка яңаларын утыртуга, шул исәптән, түбәндәге эшләрне финанслауга сарыф ителә:
- утырту материалын сатып алуга (хәзерләүгә), агач һәм куак үсентеләрен сатып алуга (хәзерләүгә), агач һәм куак үсентеләрен казып алуга, автотранспортка төяүгә һәм бушатуга, агач үсентеләренең кантарларын төрүгә, яшелләндерү өчен сатып алынган үсентеләрнең һәм орлыкларның бәясен түләүгә;
- туфракны газонны ясауга һәм агачларны, куакларны утырту өчен, планировканы, сөрүне, дисклауны, фреза белән туфракны йомшартуны, казып чыгуны, тырмалауны, туфракны тигезләүне дә кертеп, хәзерләүгә;
- агачлар һәм куаклар утырту өчен чокырлар һәм канаулар (траншеялар) казуга;
- агачларны, куакларны утыртканда, газоннарны ясаганда, туфракны 25, 50 яки 100 процентка алыштыруга;
- биологик материал, агач рәшәткә, чирәм, кәс кулланып (аның бәясен кертеп) откосларны ныгытуга;
- үсентеләр утырту урыннарын әзерләгәндә һәм газоннар ясаганда туфракка органик һәм минераль ашламалар кертүгә;
- әзер чокырларга һәм траншеяларга агачлар һәм куаклар утыртуга;
- үлән орлыкларын, гидрочәчүне дә кертеп, чәчүгә, чирәм салуга;
- вертикаль яшелләндерү буенча эшләргә;
- газон үләннәре орлыкларын чәчүгә.

3.4. Бетерелгән (киселгән) яшел утыртмалар өчен кергән акчаны башка максатларда файдалану тыела.